ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА СОВЕТЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
Советы

**КАРАР** **КАРАР**

2019 елның 18 ноябре

Кукмара шәһәре

№ 255

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Уставының 51 статьясына прокурорның 2009 елның 19 июнендәге 02-08-02/2019 номерлы протестын карап, Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәт бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), төзелешне тормышка ашырганда объектларны файдалануга тапшыруга, җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, җирлекне муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм җир кишәрлекләрен алу, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карап чыгу һәм мондый тикшерү барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирү, планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше

объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе турында һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә), планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве турында һәм (яки) җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкин түгеллеге турында хәбәрнамә, җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә, төзелгән яки үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында хәбәрнамәләр җибәрү, максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар кабул итү, үзирекле корылманы сүтүне яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру;

1.2. 40 статьяда:

а) 6.1. өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Депутат «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләре «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акчаларны һәм кыйммәт әйберләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, вазыйфалар үтәлмәгән очракта, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкача каралмаган булса, вакытыннан алда туктатыла".

б) түбәндәге эчтәлекле 6.2 өлешен өстәргә:

«7. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән

депутатка, әгәр бу мәгълүматны бозып күрсәтсәтүләр җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны җирлекнең вәкиллекле органындагы вазыйфасыннан үз вәкаләтләре вакыты туктатылганчы җирлекнең вәкиллекле органында вазыйфа биләүгә хокукын югалтып азат итү;

3) вәкаләтләре вакыты туктатылганчы, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү белән даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре срогы туктатылганчы җирлекнең вәкиллекле органында вазыйфа биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 6.3 өлешен өстәргә:

«6.3. Депутатка карата әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

1.3. 51 статьяның 6 пунктында «район Башлыгы белән килешү буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 85 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль бурыч алулар дигәндә ачык-хокукый берәмлек исеменнән ачык-хокукый берәмлек бюджетына алар буенча заемчы буларак ачык-хокукый берәмлекнең бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру юлы белән һәм кредитлар рәвешендә заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла.»;

1.5. 88 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, халык алдында норматив йөкләмәләрне билгели торган хокукый актлар нигезләмәләрен үтәүне һәм физик затларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан башка түләүләр буенча йөкләмәләр, шулай ук бюджеттан акча бирү турында дәүләт (муниципаль) контрактлары, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.»;

б) 2 өлештә «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар, үз көченә керүнең башка вакытлары законнар белән каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Район Башлыгы Димитриев С. Д.